ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 40 статьяның 1 өлешендә “электрон саклагычларда” сүзләрен “әлеге Законның $41^{1}$ статьясында каралган дәүләт мәгълүмат системаларының белешмәләр базаларында” сүзләренә алмаштырырга;

2) 41 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
“3. Кадрлар эшендә әлеге Законның $41^{1}$ статьясында каралган дәүләт мәгълүмат системалары файдаланыла.”;

3) 6 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $41^{1}$ статья өстәргә:
“$41^{1}$ статья. **Дәүләт хезмәтендә файдаланыла торган дәүләт мәгълүмат системалары**

Дәүләт хезмәтен мәгълүмати тәэмин итү һәм дәүләт органнарының кадрлар хезмәтләре эшен оптимальләштерү максатларында дәүләт хезмәте өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты указы белән дәүләт мәгълүмат системасы

төзелә һәм файдаланыла. Әлеге система дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән ярашырлык һәм дәүләт органнарын кадрлар белән тәэмин итү турында саклanырга, эшкәртелергә һәм электрон рәвештә тапшырылырга тиешле белешмәләрнең күләменә һәм эчтәлегенә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән унификацияләнгән таләпләргә туры килерлек булырга тиеш.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 20-ТРЗ